**Дәүләт хезмәте тумыштан бирелгән сәләт кебек...**

**(“Дәүләт хезмәткәре бүген” интервьюлар циклыннан)**

*Үзенең эше һәм дәүләт граждан хезмәте турында Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы урынбасары – Гаянов Рафаил Гатаулла улы сөйли.*



**- Рафаил Гатауллович, хәерле көн! Үзегезнең хезмәт стажыгыз турында сөйләгез әле, Сезнең беренче эшегез нәрсәдән гыйбарәт иде?**

- Мин 17 яшьтә Казан шәһәренең “Сантехдеталь” заводында слесарь булып эшли башладым. Казан инженерлык-төзелеш институтын тәмамлаганнан соң һәм Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач мастер, Казан шәһәрендәге С.П. Горбунов ис. Казан авиация заводының бүлек башлыгы, Казан ш. Ленин РК КПСС бүлеге инструкторы, Казан ш. Яңа Савин районы хакимияте башлыгы урынбасары, ТР Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе бүлеге башлыгы булдым. Минем хезмәт стажым – 40 ел.

**– Сезнең дәүләт һәм муниципаль хезмәттәге стажыгыз – 31 ел. “Түрә – дәрәҗәле яңгырый” дигән гыйбарә белән килешәсезме?**

– Әлбәттә, мин әлеге гыйбарә белән килешәм. Җәмгыятьнең үз сыйфаты аның мәнфәгатьләрен кайгыртучы һәр дәүләт хезмәткәренең эш сыйфатына бәйле. Без – дәүләт хезмәткәрләре дәүләт һәм халык арасындагы бәйләүче бәҗра булып торабыз. Кешеләрнең дәүләт аппаратына булган мөнәсәбәте нәкъ менә безгә бәйле. Шуңа күрә намуслы хезмәт итү, дәүләт хезмәткәре исемен горурлык һәм абруй белән йөртү – безнең бурыч булып тора.

**– Сез әле совет чорында ук дәүләт органнарында эшләгәнсез. Үткәннәр белән чагыштырганда, дәүләт хезмәткәрләре торышында нинди үзгәрешләрне билгеләп үтә алыр идегез?**

– Бүген дәүләт хезмәткәрләренең күп кенә дәүләт гарантияләре бар. Алардан медицина иминиятләвен, дәүләт хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләвен, диспансерлаштыруны оештыруны, өстәмә һөнәри белем бирүне тәэмин итүне һ.б. билгеләп үтәргә була.

**– Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 16 маендагы № 479-ПУ Указы белән “Татарстан Республикасының иң яхшы дәүләт граждан хезмәткәре” Республика конкурсы турында Нигезләмә расланды. Әлеге конкурс**

**республикадагы дәүләт граждан хезмәткәрләренең абруен үстерү, иң яхшы һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә ия булган дәүләт хезмәткәрләрен ачыклау һәм бүләкләү максатларында үткәрелә. Әлеге конкурска карата Сезнең мөнәсәбәтегез?**

– Минем карашка бу конкурс кирәк һәм ул бик тә файдалы, чөнки иң белемле һәм тәҗрибәле, югары һөнәри сыйфатларга ия булган граждан хезмәткәрләрен ачыкларга ярдәм итә.

**– Рафаил Гатауллович, фикерләрегез өчен рәхмәт. Һәм соңгысы, яшь дәүләт хезмәткәрләренә аларның җиңел булмаган һәм җаваплы эшендә нинди теләкләрегезне җиткерер идегез?**

– Коллегалар, сезгә чын күңелдән республикабыз өчен намус белән хезмәт итүегезне, алдыгызга куелган бурычларны җаваплы башкаруыгызны, командада эшли белүегезне, гадел булуыгызны, толерантлы һәм ярдәмчел булыгызны телим.

---

Гаянов Рафаил Гатаулла улының бүләкләре:

— Казан ш. Яңа Савин районы Хакимиятенең мактау грамоталары,
— “Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе” мактаулы исеме,
— Казан шәһәре хакимияте Башлыгының мактау грамоталары,
— ТР Премьер-министрының Рәхмәт хатлары,
— “Казанның 1000 еллыгы истәлегенә” медале,
— Казан ш. мэрының мактаулы грамотасы,
— ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының мактау грамотасы.

***ТР ДТКИ матбугат хезмәте***